РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«28» август 2020 г. г. Альметьевск № 390

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 338 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләрне (бюджетара трансфертларның башка рәвешләрен) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торучы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Ачыклау тәртибендә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2019 елның 16 декабрендәге 338 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан максатчан билгеләнештәге субсидияләрне (бюджетара трансфертларның башка рәвешләрен) финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торучы шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләре турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтада:

1.1.1. 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Максатчан билгеләнештәге бюджетара трансфертлар җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә.»

1.1.2. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан район бюджетына бирелә торган субсидия (башка бюджетара трансфертлар) акчалары исәбеннән бирелә.»;

1.1.3. 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы бюджетыннан район бюджетына бирелә торган субсидияләрнең (башка бюджетара трансфертларның) максатчан билгеләнеше нигезендә шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына бирелә.»;

1.1.4. 10 пунктта түбәндәге эчтәлекле «б» пунктчасы естәргә:

Заказ № 1146-100

«б) башка бюджетара трансфертлар елешендә (җирлекләрнең бюджет тәэмин ителеше дәрәҗәсен тигезләүгә дотацияләрдән тыш) - район башкарма комитеты исәпләүләре буенча.»;

1.1.5. 14 пунктта түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә: «Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре шушы максатларга акчалар бирү турында Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнә.»

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник», газетасында бастырырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның нигезләмәләре, 2020 елга, 2021 һәм 2022 еллар план чоры бюджетларыннан башлап, бюджетларны төзегәндә, раслаганда һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны район Советының бюджет-финанс мәсьәләләре, җирле салымнар һәм җыемнар буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Мусин Р.Ф.).

Муниципаль район Башлыгы Т.Д. Нагуманов

«СОВЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА»